ЯШӘРТӘ ТОРГАН АЛМАЛАР ҺӘМ ТЕРЕЛТӘ ТОРГАН СУ ТУРЫНДА ӘКИЯТ



ТАТГОСИЗДАТ 1952

ЯШӘРТӘ ТОРГАН АЛМАЛАР ҺӘМ ТЕРЕЛТӘ ТОРГАН СУ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕ

А. ТОЛСТОЙ эшләнешендә


Н. ТАҖЕТДИНОВ тәрҗемәсе

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1952

ӘКИЯТ БАШЫ

Ниндидер бер диңгездә, Буян утравында, алтын чикләвекле зур бер агач бар, ди, бу агачта Баюн-песи йөри, ди, өскә менеп — җырлар җырлый, түбән төшеп — әкиятләр сөйли, ди. Бу әкият түгел әле, әкиятнең башы гына, әкият үзе алда булачак. Әкият иртә белән, аштан соң йомшак икмәк ашагач, сөйләнәчәк.



Ниндидер бер патшалыкта, ниндидер бер илдә бер патша яшәгән, аның булган өч улы: өлкәне — Фёдор, уртанчысы — Василий, ә кечесе Иван исемле икән.

Патша бик картайган, күзләре дә начар күрә башлаган, ә ул Каф тавы артында, утызынчы патшалыкта яшәртә торган алмалар үскән бакча һәм терелтә торган сулы кое барлыгын ишеткән. Әгәр карт кеше бу алманы ашаса — яшәрә, сукыр кеше бу су белән күзен юса — күрә башлый икән.

Патша сый-хөрмәткә бөтен дөньядан князьләрне, бай-түрәләрне чакырган да аларга:

— Иң яхшы егетләрнең кайсы Каф тавы артына, утызынчы патшалыкка барып яшәртә торган алмалар, унике авызлы чүлмәк эчендә терелтә торган су алып кайтырга риза булса, мин шул егеткә ярты патшалыгымны бирер идем, — дигән.

Өлкәне уртанчысына, уртанчысы кечесенә салына башлаган, ә кечесеннән җавап юк.

Патша улы Фёдор чыккан да:

— Безнең патшалыкны кешегә бирәсебез килми. Бу юлга үзем чыгам, сиңа, патша-атакайга, яшәртә торган алмалар белән уникe авызлы чүлмәк эчендә терелтә торган суны үзем алып кайтам, — дигән.

Патша улы Фёдор, ат абзарына кереп, үзенә моңарчы бер дә җигелмәгән ат сайлап алган, аны йөгәнләнмәгән йөгән белән йөгәнләгән, камчыланмаган камчы алган, матурлык өчен түгел, нык булсын өчен уникe алтын аеллы ияр белән иярләгән... Шулай итеп патша улы Фёдор юлга чыгып киткән. Атка атланганын күргәннәр, ә кайсы якка чабып киткәнен күрми дә калганнар.

Ай киткән, ел киткән, күктә очкан, җирдән барган, иртәдән кичкә кадәр, таңнан кояш баеганчы барган. Аннары өч юл чатына килеп җиткән. Юл чатында бер таш ята икән, ә ташка:

„Уңга барсаң — үзеңне коткарырсың, атыңны югалтырсың, сулга барсаң — атыңны коткарырсың, үзеңне югалтырсың, туп-туры барсаң — өйләнәсең“, — дип язылган икән.

Патша улы Фёдор уйлап-уйлап торган да: „Әйдә, өйләнәсең дигән юл белән барыйм әле“, — дигән.

Өйләнәсең, дигән юлга борылган. Барган-барган да алтын түбәле бер сарай янына килеп җиткән. Сарайдан бик гүзәл бер кыз йөгереп чыккан да:

— Патша улы, мин сине ияреңнән төшерәм, әйдә, минем белән кунак булырсың, рәхәтләнеп йокларсың, — дигән.

— Юк, кызыкай, кунак буласым килми, ә йоклап мин юлымны кыскарта алмыйм. Миңа алга барырга кирәк.

— Патша улы, китәргә ашыкма, җаның теләгән нәрсәне эшләргә ашык.

Гүзәл кыз шундук аны ияреннән төшергән дә үзенең өенә алып кереп киткән. Ашаткан, эчерткән, урын җәеп йокларга яткырган.

Патша улы Фёдор стена буена ятуы булган, теге кыз кроватьны тиз генә әйләндереп тә җибәргән, патша улы Фёдор идән астына, тирән чокырга төшеп киткән...

Азмы-күпме вакыт үткән — патша тагын сый-хөрмәткә князьләрне, бай-түрәләрне җыйган да аларга:

— Менә, егетләр, кайсыгыз Каф тавы артына, утызынчы патшалыкка барып яшәртә торган алмалар белән унике авызлы чүлмәк эчендә терелтә торган су алып кайтырга риза булса, мин шул егеткә ярты патшалыгымны бирер идем, — дигән.

Тагын өлкәне уртанчысына, уртанчысы кечесенә салына башлаган, ә кечесеннән җавап юк.

Икенче улы, патша улы Василий чыккан да:

— Атакай, патшалыкны чит кеше кулына бирәсем килми. Юлга үзем чыгам, ул әйберләрне үзем алып кайтып кулыңа тоттырам, — дигән.

Патша улы Василий, ат абзарына кереп, үзенә моңарчы бер дә җигелмәгән ат сайлап алган, аны йөгәнләнмәгән йөгән белән йөгәнләгән, камчыланмаган камчы алган, атын унике аеллы ияр белән ияләгән.

Патша улы Василий юлга чыгып киткән. Атка атланганын күргәннәр, ә кайсы якка киткәнен күрми дә калганнар.

Менә ул теге таш яткан юл чатына килеп җиткән. „Уңга барсаң — үзеңне коткарырсың, атыңны югалтырсың, сулга барсаң — атыңны коткарырсың, үзеңне югалтырсың, туп-туры барсаң, өйләнерсең“, дигән язуны күргән.

Патша улы Василий уйлап-уйлап торган да, „өйләнәсең“ дигән туры юл белән киткән. Алтын түбәле сарайга килеп җиткән. Аның каршысына бик гүзәл бер кыз йөгереп чыккан һәм аны кунакка, ял итеп чыгарга чакырган.

— Патша улы, китәргә ашыкма, җаның теләгән нәрсәне эшләргә ашык, — дигән.

Патша улы Василийны ияреннән төшергән дә сарайга алып кереп киткән, ашаткан, эчерткән, йокларга яткырган.

Патша улы Василийның стена буена ятуы булган, теге кыз тагын кроватьны әйләндереп җибәргән, патша улы Василий идән астына төшеп тә киткән.

Ә идән астыннан:

— Кем очып төшә? — дип сорыйлар.

— Патша улы Василий. Ә кем утыра?

— Патша улы Фёдор.

— Менә, абзыкай, эләктек!

Азмы-күпме вакыт үткән, патша өченче тапкыр сый-хөрмәткә князьләрне, бай-түрәләрне чакырган да аларга:

— Кем яшәртә торган алмалар белән унике авызлы чүлмәк эчендә терелтә торган су алып кайтырга риза булса, мин шул егеткә ярты патшалыгымны бирер идем, — дигән.

Тагын өлкәне уртанчысына, уртанчысы кечесенә салына башлаган. Ә кечесеннән җавап юк.

Патша улы Иван чыккан да:

— Атакай, кыю башым, җитез аякларым белән утызынчы патшалыкка барып сиңа яшәртә торган алмалар белән терелтә торган суны һәм ике абыемны эзләп алып кайтырга миңа ризалыгыңны бир, — дигән.

Патша ризалык биргән. Патша улы Иван үзенә ошаган атны сайларга ат абзарына киткән. Кайсы атка карамасын — шул ат калтырана башлый, кайсына кулын куймасын — шул ат аяктан егыла икән...

Патша улы Иван үзенә ошаган ат сайлап ала алмаган. Башын аска иеп бара бу. Аңа каршы йорт караучы әби очраган да:

— Исәнме, балакаем, Иван-царевич! Нигә кайгыга батып, хәсрәтләнеп йөрисең? — дип сораган.

— Нигә кайгырмаска, әби, үземә ошаган ат таба алмыйм.

— Күптән миннән сорарга кирәк иде. Яхшы ат богауланган, тимер чылбырга бәйләнгән килеш базда тора. Аны алып чыга алсаң — син теләгән ат булачак.

Патша улы Иван баз янына килгән дә тимер капкачны тибеп җибәргән, капкач читкә атылган, баз

ачылып киткән. Ул бер яхшы ат янына килеп кергән, ат алгы аякларын аның җилкәсенә куйган. Патша улы Иван селкенмәгән дә. Ат тимер чылбырны өзеп баздан сикереп чыккан да патша улы Иванны да үзе белән өстерәгән. Шунда патша улы Иван атны йөгәнләнмәгән йөгән белән йөгәнләгән, иярләнмәгән ияр белән иярләгән, матурлык өчен түгел, ә яшь егетнең даны өчен, унике аел алган.

Шулай итеп патша улы Иван юлга чыгып киткән. Атка атланганын күргәннәр, ә кайсы якка киткәнен күрми калганнар... Юл чатына килеп җиткән дә уйга калган:

„Уңга китсәң — атыңны югалтырсың, — ә атсыз мин кая барыйм? Туп-туры барсаң — өйләнерсең, — өйләнер өчен юлга чыкмадым мин. Сулга барсаң — атыңны коткарырсың — менә минем өчен иң яхшы юл“.

Ул „атыңны коткарырсың, үзеңне югалтырсың“ дигән юлга борылган. Азмы-күпме вакыт узган, яшел болыннардан, ташлы таулардан иртәдән кичкә, таңнан кояш баеганчы барган-барган да бер өй янына килеп җиткән, ди.

Бу өй бер генә тәрәзәле, ди, үзе тавык аягы өстендә тора, ди.

— Өйкәй, өйкәй, урманга артың, миңа алдың белән әйлән! Мин сиңа кереп кенә чыгам.

Өй урманга арты белән, патша улы Иванга алды белән әйләнгән. Патша улы Иван өйгә кергән, ә анда бик карт бер убырлы карчык утыра, ди, ул ефәк чөя, ә аларны киртәгә элеп куя, ди.



— Фу, фу, күз күрмәгән, колак ишетмәгән адәм бүген үзе килгән.

Ә патша улы Иван аңа:

— Ах син, убырлы карчык, сөяк аяк, тотмас борын кошны йолкыйсың, белмәс борын егетне хурлыйсың... Син хәзер урыныңнан сикереп торып мине, яхшы егетне, юл кешесен ашатыр, эчертер идең, йоклар өчен урын әзерләр идең. Мин ятып торыр идем, ә син баш очыма утырып минем кем булуымны, кайдан килүемне сорашыр идең,—дигән.

Убырлы карчык бу эшләрнең барысын да эшләгән—патша улы Иванны ашаткан, эчерткән, урынга яткырган. Баш очына утырган да сораша башлаган:

— Кем улы син, юл кешесе, яхшы егет, кайдан киләсең? Кайсы илдән? Атаң-анаң кем?—дигән.

— Мин, әби, патша улы Иван, фәлән патшалыктан, фәлән илдән, Каф тавына, Каф тавындагы күлләр артына, утызынчы патшалыкка терелтә торган су белән яшәртә торган алмалар алырга барам.

— Я, сөекле балакаем, юлың бик ерак икән; терелтә торган су белән яшәртә торган алмалар бик көчле, баһадир кыз—Зәңгәркүз кулында, ул минем бертуган кардәшемнең кызы. Белмим, син бу әйберләрне ала алырсың микән?..

— Ә син, әби, үзеңнең башыңны минем көчле җилкәмә куй да миңа акыл өйрәт.

— Бик күп егетләр узып киткәләделәр, ләкин бик азы гына ягымлы сөйләште. Минем атымны ал да, балакай, апам янына бар. Ул сиңа нишләргә кирәген миннән яхшырак өйрәтер.

Патша улы Иван иртән иртүк йокысыннан торган да әйбәтләп юынган. Кундырган өчен әбигә рәхмәт әйтеп, аның атына атланып чыгып киткән, ди.

Кинәт ул атка:

— Тукта! Перчаткамны төшердем, — дигән.

Ә ат аңа:

— Син әйтеп бетергәнче, мин ике йөз чакрым җир чабып киттем инде, — дигән.

Патша улы Иван ай киткән, ел киткән. Көн артыннан төн үткән. Каршында бер өй күргән, өй бер генә тәрәзәле, ди, үзе тавык аягы өстендә тора, ди.

— Өйкәй, өйкәй, урманга артың, миңа алдың белән әйлән! Мин сиңа кереп кенә чыгам.

Өй урманга арты, аңа алды белән әйләнгән.

Кинәт бер ат кешнәп җибәргән. Патша улы Иванның аты да аңа каршы кешнәгән.

Бер көтүдә йөргән атлар икән.

Моны әвәлгесеннән дә картрак бер убырлы карчык ишеткән дә:

— Апам миңа кунакка килгән, күрәсең, — дигән.

Убырлы карчык өй алдына чыккан да:

— Фу, фу, күз күрмәгән, колак ишетмәгән адәм бүген үзе монда килгән, — дигән.

Ә патша улы Иван аңа:

— Ах син, убырлы карчык, сөяк аяк, кунакны киеменә карап каршы ал, акылына карап озат. Син минем атны бәйләп куй, мине, яхшы егетне, юл кешесен, ашат, эчерт, йокларга яткыр, — дигән.

Убырлы карчык бу эшләрнең барысын да эшләгән — атны бәйләп куйган, патша улы Иванны ашат-

кан, эчерткән, йокларга яткырган да аның кем булуын, кайдан килүен, кая баруы турында сораша башлаган, ди.

— Мин, әби, фәлән патшалыктан, фәлән илдән. Патша улы Иван мин. Терелтә торган су белән яшәртә торган алмалар алырга көчле баһадир кыз — Зәңгәркүз янына барам.

— Я, балакаем, бу әйберләрне ала алырсың микән. Сиңа Зәңгәркүз янына барып җитүе бик читен булачак.

— Ә син, әби, үзеңнең башыңны минем көчле җилкәмә куй да акыл өйрәт.

— Бик күп яшь егетләр узып киткәләделәр, ләкин бик азы гына ягымлы сөйләште. Балакаем, минем атымны ал да апам янына бар. Нәрсә эшләргә кирәклеген ул миннән дә яхшырак өйрәтер.

Патша улы Иван бу әбидә бер генә кич кунган да иртән иртүк торып бик яхшылап юынган. Кундырган өчен убырлы карчыкка рәхмәт әйтеп, аның атына атланып чыгып киткән, ди. Бу ат тегесеннән дә җитезрәк булган, ди.

Кинәт патша улы Иван аңа:

— Тукта! Перчаткамны төшердем, — дигән.

Ә ат:

— Син әйткән арада мин өч йөз чакрым җир чаптым инде, — дигән.

Әкият тиз сөйләнсә дә, эш алай ук тиз эшләнми. Патша улы Иван иртәдән кичкә кадәр, таңнан кояш баеганчы барган. Бер өй янына килеп җиткән, өй бер генә тәрәзәле, ди, үзе тавык аягы өстендә тора, ди.

— Өйкәй, өйкәй, урманга артың, миңа алдың белән әйлән! Мин озак тормыйм, бер генә кич кунып чыгам.

Кинәт бер ат кешнәп җибәргән, патша улы Иванның аты да моңа җавап биргән. Өй алдына тегесеннән дә картрак бер убырлы карчык килеп чыккан. Караса — ат сеңелесенеке, ә атланган кеше — чит кеше, бик чибәр бер егет...

Патша улы Иван әдәпле генә итеп аңа башын игән дә кунып чыгарга рөхсәт сораган. Берни эшләр хәл юк! Куна торган урынны үзең белән йөртеп булмый, ә куна торган урын һәркемгә кирәк: җәяүлегә дә, атлыга да, байга да, ярлыга да.

Убырлы карчык бөтенесен эшләгән, ди — атны бәйләп куйган, патша улы Иванны ашаткан, эчерткән дә аның кем булуы, кайдан килүе һәм кая баруы турында сораша башлаган, ди.

— Мин, әби, фәлән патшалыктан, фәлән илдән. Патша улы Иван мин. Синең кече сеңелеңдә булдым, ул уртанчы сеңелесенә җибәрде, уртанчы сеңелегез сиңа җибәрде. Үзеңнең башыңны минем көчле җилкәмә куй да, Зәңгәркүздән ничек итеп терелтә торган су белән яшәртә торган алмаларны алырга акыл өйрәт.

— Ярый алайса, ярдәм итим инде мин сиңа, патша улы Иван. Зәңгәркүз минем бертуган кардәшемнең кызы — көчле, куәтле баһадир. Аның патшалыгы өч сажен биеклектәге, бер сажен калынлыктагы койма белән әйләндереп алынган, капка төбендә утыз баһадир сакчы тора, алар сине капкадан кертмәсләр,



синa төн уртасында минем яхшы атым белән китәргә кирәк. Койма янына җиткәч, атның ике ягынада камчыланмаган камчы белән сук. Ат койма аркылы сикереп чыгар. Атны бәйләп куй да бакчага кер. Яшәртә торган алмалы алмагач, ә аның төбендә бер кое күрерсең. Өч кенә алма ал, аннан артыгын алма. Аннан соң унике авызлы чүлмәк белән коедан су чумырып ал. Зәңгәркүз йоклаган булыр, син аның йортына кермә, атка атлан да камчы белән кабыргасын сыдыр. Ат сине койма аркылы кире алып чыгар.

Патша улы Иван бу карчыкта йокларга калмаган, аның яхшы атына атланган да юлга чыгып киткән, ди. Ат сазлык, баткаклыклардан сикереп, елгаларны, күлләрне койрыгы белән себереп, сикерә-сикерә чапкан, ди.

Азмы-күпме вакыт үткәч, төн уртасында биек койма янына килеп җиткән. Капка янында утыз баһадир сакчы йоклап ята икән. Патша улы Иван үзенең яхшы атына ныгытып утырган да аны камчыланмаган камчы белән кыйнаган. Ат ачуланып койма аркылы сикереп чыккан. Патша улы Иван атыннан төшеп бакчага кереп караса — көмеш яфраклы, алтын алмалы алмагач, ә алмагач астында бер кое күргән. Патша улы Иван өч алма өзеп алган, артыгын өзмәгән, унике авызлы чүлмәк белән коедан су чумырып алган. Шул вакыт аның көчле, гайрәтле, баһадир кыз — Зәңгәркүзнең үзен күрәсе килә башлаган.

Патша улы Иван өйгә кергән, ә өйдә унике ба-

һадир кыз уртасында шарлавык ургыган тавыш чыгарып Зәңгәркүз йоклап ята икән.

Патша улы Иван түзмәгән, Зәңгәркүзне үпкән дә чыгып киткән... Яхшы атына атланган икән, ат телгә килеп, аңа:

— Сүземне тыңламадың, патша улы Иван, Зәңгәркүз янына өйгә кердең! Хәзер мин койманы сикереп чыга алмыйм инде, — дигән.

Патша улы Иван камчыланмаган камчы белән атны кыйный башлаган.

— Ах син, ат, бүре азыгы, үлән капчыгы, безгә монда кунарга ярамый, башыңны югалтырсың!

Ат элеккедән дә катырак ачуланып койма аркылы сикергәндә, бер дагасы коймага бәрелгән — коймадагы тимер чыбыклар зыңлап куйган, кыңгыраулар шалтырый башлаган.

Зәңгәркүз уянган да карак килгәнен күреп:

— Торыгыз, караклар бар! — дип кычкырган.

Үзенең баһадир атын иярләргә кушкан һәм унике баһадир белән патша улы Иванны куа киткән, ди.

Патша улы Иван җан-фәрманга атын куган, ә Зәңгәркүз аның артыннан чапкан. Патша улы Иван убырлы карчык янына килеп җиткән. Анда икенче ат юлга әзерләнеп куелган булган. Ул бер аттан төшеп икенчесенә атланган да тагын алга чапкан... Патша улы Иван ишектән чыгып киткәч тә Зәңгәркүз килеп кергән һәм убырлы карчыкка:

— Әби, моннан берәр җанвар узмадымы? — дигән.

— Юк, балакаем.

— Әби, моннан берәр егет узып китмәдеме?

— Юк, балакаем. Ә син юл уңаенда гына булса да сөт ашап кит.

— Ашар идем дә бит, сыерны озак саварсың шул.

— Нәрсә син, балакаем, хәзер савып алам...

Убырлы карчык сыерны ашыкмыйча гына сауган, ди. Зәңгәркүз сөт ашаган да тагын патша улы Иванны куа киткән, ди.

Патша улы Иван уртанчы убырлы карчык янына килеп җиткән, атын алыштырган да тагын киткән. Аның чыгып китүе булган—Зәңгәркүз ишектән кергән дә:

— Әби, берәр җанвар узып китмәдеме, берәр яхшы егет узып китмәдеме?—дигән.

— Юк, балакаем. Син юл уңаенда гына булса да коймак ашап ал.

— Син озак пешерерсең шул.

— Нәрсә син, балакаем, бик тиз пешереп алам...


Убырлы карчык ашыкмыйча гына коймак пешергән, ди. Зәңгәркүз ашаган да тагын патша улы Иванны куа киткән, ди.

Патша улы Иван кече убырлы карчык янына килеп җиткән, үзенең баһадир атына атланган да тагын чапкан. Аның ишектән чыгып китүе булган, Зәңгәркүз килеп кергән дә убырлы карчыктан:

— Берәр яхшы егет узып китмәдеме?—дип сораган.

— Юк, балакаем. Син юл уңаенда гына булса да мунча кереп чык.

— Син озак ягарсың шул.
— Нәрсә син, балакаем, хәзер ягып өлгертәм...
Убырлы карчык мунча яккан, барысын да әзерләп куйган, ди. Зәңгәркүз парланган, юынган да тагын патша улы Иванны куа киткән, ди. Аның аты таулардан тауларга сикергән, елгаларны, күлләрне коерыгы белән себергән. Менә ул патша улы Иванны куып җитә башлаган.
Патша улы Иван унике баһадир кыз, унөченче — Зәңгәркүз кызның үзен куып җитүләрен, өстенә ташланып башын өзәргә уйлауларын күргән. Ул атын туктата башлаган, Зәңгәркүз атын чаптырып килгән дә:
— Нәрсә син, карак, сорамыйча минем коемнан су эчтең, җитмәсә, япмыйча калдыргансың? — дип кычкырган.
Ә Иван аңа:
— Нәрсә, әйдә ул чагында, өч ат адымы кадәр ераклыктан көчебезне сынап карыйк, — дигән.
Патша улы Иван белән Зәңгәркүз сугыша торган чукмарларын, озын сөңгеләрен, үткен кылычларын алып өч ат адымы җир киткәннәр, ди. Өч мәртәбә кара-каршы очрашканнар, чукмарларын сындырганнар, сөнге-кылычларын кытыршылап бетергәннәр — бер-берсен ат өстеннән бәреп төшерә алмаганнар. Яхшы ат өстендә йөрүнең кирәге булмагач, алар атларыннан сикереп төшкәннәр дә берберсен эләктереп алганнар.
Иртәдән кичкә, таңнан кояш баеганчы көрәшкәннәр. Иванның җитез аягы таеп киткән дә, ул



җиргә егылган, ди. Зәңгәркүз кыз аның ак күкрәгенә тезләнгән дә корыч хәнҗәрен чыгарып аның ак күкрәгенә чәнечмәкче булган, ди. Патша улы Иван аңа:

— Харап итмә мине, Зәңгәркүз кыз, мине ак кулларымнан тотып юеш җирдән торгыз да татлы иреннәремнән үп, — дигән.

Шунда Зәңгәркүз кыз аны күтәреп торгызган, татлы иреннәреннән үпкән, ди. Алар киң кырда, яшел болынлыкта чатыр корып җибәргәннәр, ди. Өч көн, өч төн күңел ачканнар. Шунда өйләнешкәннәр, йөзекләрен алмашканнар, ди.

Зәңгәркүз кыз патша улы Иванга:

— Мин өемә кайтам — син дә өеңә кайт, кара аны, бер кая да кермә...Өч елдан соң мине үзеңнең патшалыгыңда көт, — дигән.

Алар атларына атланганнар да аерылышканнар...

Азмы-күпме вакыт үткәч, әкият тиз сөйләнсә дә, эш алай ук тиз эшләнми, — патша улы Иван өч юл чатына, таш яткан җиргә килеп җиткән дә уйга калган.

„Ярый инде! Үзем өйгә кайтам, ә абыйларым хәбәрсез югалалар“.

Ул, Зәңгәркүз кызның сүзен тыңламыйча, „өйләнәсең“ дигән юлга борылган... Алтын түбәле сарайга килеп җиткән. Шунда патша улы Иванның аты кешнәп җибәргән. Абыйларының атлары да моңа каршы кешнәп җибәргәннәр, ди. Бер көтүдәге атлар икән...

Патша улы Иван баскычка менеп бөҗра белән суккан икән, сарайның түбәсе селкенеп киткән, тәрәзә кысалары кәкрәйгәннәр. Бер гүзәл кыз йөгереп чыккан да:

— Ах, Иван, мин сине күптән көтәм! Әйдә миндә кунак бул, ял итеп ал,—дигән.

Иванны сарайга алып кергән дә кыстый-кыстый сыйлаган. Патша улы Иван ашаганга караганда ашамлыкларын күбрәк өстәл астына ташлаган, ди, эчемлекләрен күбрәк өстәл астына түккән, ди. Гүзәл кыз аны йокы бүлмәсенә алып кергән дә:

— Йокларга ят, Иван,—дигән.

Ә патша улы Иван аның үзен кровать өстенә этеп еккан да тиз генә кроватьны әйләндереп җибәргән, ди, әлеге кыз идән астына, тирән чокырга төшеп киткән, ди.

Патша улы Иван иелгән дә тишектән:

— Тере кеше бармы анда?—дип кычкырган.

Ә чокырдан:

— Патша улы Фёдор белән патша улы Василий,—дип җавап биргәннәр.

Ул аларны чокырдан тартып чыгарган, аларның йөзләре каралып беткән, җиргә әверелә башлаган икән. Патша улы Иван аларны терелтә торган су белән юган икән, алар тагын элекке хәлләренә кайтканнар, ди.

Барысы да атларына атланганнар да кайтып киткәннәр... Азмы-күпме вакыт үткәч, юл чатына килеп җиткәннәр. Иван абыйларына:

— Минем атымны саклап торыгыз, ә мин ял итеп алам, — дигән.

Ул ефәк чирәмгә яткан да баһадирларча йоклап та киткән. Ә патша улы Фёдор Василийга болай дигән:

— Әгәр без терелтә торган су белән яшәртә торган алма алып кайтмасак, безгә хөрмәт булмас, әткәй безне казлар көтәргә җибәрер...

Патша улы Василий шулай дип җавап биргән:

— Әйдә, Иванны төпсез чокырга ташлыйк та бу әйберләрне алып әткәйнең кулына үзебез бирик.

Алар патша улы Иванның кулыннан яшәртә торган алмаларны, терелтә торган сулы чүлмәкне алганнар һәм аны төпсез чокырга ташлаганнар, ди. Патша улы Иван өч көн, өч төн очып төшкән.

Иван нәкъ диңгез читенә килеп төшкән, һушына килгәч, караса — су белән күкне һәм диңгез янындагы карт имән астында чыелдап, җил-давылдан туңып-өшеп утырган кошларны гына күргән, ди.

Патша улы Иван чикмәнен салып кошлар өстенә япкан да үзе имән астына кереп яшеренгән.

Һава тынган, зур Нагай-кош очып килгән. Имән астына утырган да балаларыннан:

— Кадерле балакайларым, сезне җил-яңгыр үтермәдеме? — дип сораган.

— Кычкырма, әни, безне рус кешесе коткарып калды, өстебезгә үзенең чикмәнен япты.

Нагай-кош патша улы Иваннан:

— Син нигә монда килдең, ягымлы кеше? — дип сораган.

— Терелтә торган су белән яшәртә торган алмалар өчен мине бертуган абыйларым төпсез чокырга ташладылар.

— Син минем балаларымны саклап калгансың; алтынмы, көмешме яки берәр асыл ташмы: миннән нәрсә теләсәң, шуны сора.

— Миңа, Нагай-кош, алтын да, көмеш тә, асыл таш та — бернәрсә дә кирәкми. Миңа туган илемә кайтырга мөмкин түгелме?


Нагай-кош аңа:

— Миңа егермешәр пот ит салган ике зур чүлмәк әзерлә, — дигән.

Менә патша улы Иван диңгез буенда казлар, аккошлар аткан, аларны ике зур кисмәккә тутырган да бер кисмәкне Нагай-кошның уң як канатына, икенче кисмәкне сул як канатына куеп, үзе аның сыртына менеп утырган, ди. Патша улы Иван Нагай-кошны ашата башлаган, ә кош югарыга таба оча да оча икән.

Кош очкан, ә Иван аны ашаткан да ашаткан...

Алар шулай азмы-күпме очканнар. Патша улы Иван ике кисмәктәге итне дә ашатып бетергән, ди. Ә Нагай-кош тагын башын борган. Патша улы Иван пычак алып үзенең аягыннан бер кисәк ит кисеп алган да Нагай-кошка биргән, ди. Нагай-кош очкан-очкан да тагын башын борган. Иван-царевич икенче аягыннан ит кисеп биргән, ди. Менә очарга ерак калмаган икән инде. Нагай-кош тагын



башын борган. Патша улы Иван күкрәгеннән ит кисеп алып биргән.

Шул арада Нагай-кош патша улы Иванны туган иленә илтеп тә җиткергән, ди.

— Син мине юл буенча яхшы ашаттың, ләкин соңгы кисәк шикелле тәмле итне гомеремдә дә ашаганым юк иде.

Иван кошка үзенең яраларын күрсәткән. Нагай-кош өч кисәкне дә кире кикереп чыгарган да:

— Урынына куй,—дигән.

Патша улы Иван итне кире урынына куйган икән, ит тагын сөяккә ябышып үскән.

— Хәзер өстемнән төш инде, патша улы Иван, мин кире үз өемә очам.

Нагай-кош өскә күтәрелгән, ә Иван юл буйлап туган иленә таба киткән, ди.

Патша улы Иван башкалага килеп җиткәч, Фёдор белән Василийның аталарына терелтә торган су һәм яшәртә торган алма алып кайтулары, атасының терелүе, элеккечә таза, нык һәм күзләренең дә үткенәюе турында ишеткән.

Патша улы Иван ата-анасы янына кайтмаган, эчкечеләрне җыйган да кабакларда типтерә башлаган.

Шул вакытта Каф тавы артында, утызынчы патшалыкта көчле, баһадир Зәңгәркүз кыз ике ир бала тапкан, ди. Алар көнләп түгел, сәгатьләп үскәннәр, ди. Әкият тиз сөйләнсә дә, эш алай ук тиз эшләнми, өч ел вакыт узган. Зәңгәркүз кыз,

үзе белән улларын алган да, гаскәр җыеп, патша улы Иванны эзләргә киткән, ди.

Иван атасының патшалыгына килеп җиткән, ди. Кырда, иркен җирдә, яшел болынлыкта ак киндер чатыр корып җибәргән, ди. Чатырдан юлга бизәкле келәмнәр җәйгән, ди. Башкалага кеше җибәргән дә патшага:

— Патша, улыңны бир. Бирмәсәң, бөтен патшалыгыңны таптап бетерәм, үзеңне әсир итәм,— дип әйтергә кушкан, ди.

Патша курыккан да өлкән улы — Фёдорны җибәргән, Фёдор ак киндер чатыр янына килеп җиткән. Ике малай йөгереп чыкканнар да:

— Анакай, анакай, безнең атакай килә түгелме? — дип сораганнар.

— Юк, балакайлар, ул сезнең абзагыз.

— Аны нәрсә эшләтергә кушасың?

— Ә сез, балакайлар, аны яхшы гына сыйлагыз.

Әлеге ике малай чыбык алганнар да патша улы Фёдорны биленнән түбәнрәк җиреннән шундый каты кыйнаганнар, ди, патша улы Фёдор көчкә генә аягын өстерәп китә алган, ди.

Ә Зәңгәркүз тагын патшага кеше җибәргән:

— Патша, улыңны бир...

Патша тагын да курка төшкән, уртанчы улы — Василийны җибәргән. Патша улы Василий чатыр янына килеп җиткән. Ике малай йөгереп чыкканнар да:

— Анакай, анакай, безнең атакай килә түгелме?

— Юк, балакайларым, ул сезнең абзагыз. Аны яхшы гына сыйлагыз.

Ике малай тагын абзаларын чыбык белән кыйный башлаганнар. Патша улы Василий көчкә генә аягын өстерәп китә алган, ди.

Зәңгәркүз өченче мәртәбә патшага кеше җибәргән:

— Барыгыз, өченче улыгыз Иванны эзләгез. Тапмасагыз—бөтен патшалыкны таптап, яндырып бетерәм,—дигән ди.

Патша тагын да курка төшкән. Фёдор белән Василийны чакырган да аларга Иванны табарга кушкан, ди. Шунда алар аталарының аягына егылганнар. Йоклаган Иваннан ничек итеп терелтә торган суны, яшәртә торган алмаларны алулары һәм Иванны төпсез чокырга ташлаулары турында барысын да дөресен сөйләгәннәр, ди.

Моны ишеткәч патша бик каты елаган. Ә шул чакта патша улы Иван, кабак эчкечеләрен дә үзе белән ияртеп, Зәңгәркүз янына килгән, ди. Эчкечеләр аяк астындагы keләмне ерткалап як-якка ыргыталар икән, ди.

Патша улы Иван ак киндер чатыр янына килеп җиткән. Ике малай йөгереп чыккан да:

— Анакай, анакай, безнең янга кабактагы эчкечеләр белән нindидер бер исерек килә!—дигәннәр.

Ә Зәңгәркүз аларга:

— Аның ак кулларыннан тотып чатырга алып керегез. Ул гөнаһсызга өч ел газап чикте,—дигән.

Шулчак патша улы Иванны ак кулларыннан тотып чатырга алып кергәннәр. Зәңгәркүз аны юындырган, чәчләрен тараган, аның өс-башын алыштырган да йокларга яткырган. Кабак эчкечеләренә берәр стакан аракы эчерткән, эчкечеләр өйләренә кайтып киткәннәр.

Икенче көнне Зәңгәркүз белән патша улы Иван сарайга килгәннәр. Шунда сый-хөрмәт, туй башланган. Патша улы Фёдор белән патша улы Василийга кадер-хөрмәт булмаган, аларны сарайдан куып чыгарганнар. Бер-ике көн тегендә-монда кунып йөргәннәр. Ә соңыннан кунарга урыннары да булмаган.

Патша улы Иван монда калмаган. Зәңгәркүз белән аның кыз чагындагы патшалыгына киткән.

Әкият тә шунда беткән.



СКАЗКА О МОЛОДИЛЬНЫХ ЯБЛОКАХ И ЖИВОЙ ВОДЕ

(на татарском языке)

Обработка А. Толстого

Жаваплы редакторы *Н. Фәттахов*
Тышлык художнигы *А. Фарафонтов*
Рәсемнәр *К. В. Кузнецов* буенча

Художество редакторы *Ш. Мөхәммәтҗанов*
Техник редакторы *А. Феофилактов*
Корректоры *Л. Шайнурова*

Наборга бирелде 26/I-1952 ел. Басарга кул куелды 14/III-1952 ел. ПФ 02063. Кәгазь форматы 70×92 1/16-1,0 к. т. Учет-изд. 1.08 табак. Басма табак 2.34. Табакта 47900 хәреф. Заказ № 038. Тираж 8000+65

1952 нче ел прейскуранты буенча бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Полиграфия промышленносте, издательстволар һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Татполиграф типографиясе, Казан, Миславский ур., йорт 9.

1952 нче елгы яңа бәя
40 тиен.